# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20 ноябрь 2024 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 ( бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:**

- кышкы чорда Бикмәч авылындагы юлларны карап тоту өчен тракторчы хезмәтләре өчен түләү, Первомайская, Лесная урамнарын, зират юлын кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Беренче Май, Урман урамнарын, зират юлын җәйге чорда карап тоту өчен хезмәт күрсәтүләр өчен тракторчыга түләү;
- Беренче Май, Урман урамнарын, зират юлын грейдировкалау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

**2) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, ремонтлау:**

- зираттан каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау;
- күмелгән Бөек Ватан сугышы ветераннарының исемлеген әзерләү һәм урнаштыру.

**3) урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен**

**тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**
- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу.

**4) торак пункт территориясен төзекләндерү:**
- үлән чабу.

**5) РФ халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**
- Бөек Ватан сугышы истәлеге һәйкәлен ремонтлау.

**6) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү:**
- «Миннегарей» чишмәсен киртәләү өчен материал сатып алу, күпер өчен металл конструкцияләр әзерләү һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 43 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 23, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 21 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең Бикмәч торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 (җиде йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга җибәрергә:

**1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:**
- кышкы чорда Бикмәч авылындагы юлларны карап тоту өчен тракторчы хезмәтләре өчен түләү, Первомайская, Лесная урамнарын, зират юлын кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Беренче Май, Урман урамнарын, зират юлын җәйге чорда карап тоту өчен хезмәт күрсәтүләр өчен тракторчыга түләү;

- Беренче Май, Урман урамнарын, зират юлын грейдировкалау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

**2) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, ремонтлау:**

- зираттан каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау;
- күмелгән Бөек Ватан сугышы ветераннарының исемлеген әзерләү һәм урнаштыру;

**3) урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу;

**4) торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үлән чабу;

**5) РФ халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- Бөек Ватан сугышы истәлеге һәйкәлен ремонтлау;

**6) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү:**

- «Миннегарей» чишмәсен киртәләү өчен материал сатып алу, күпер өчен металл конструкцияләр әзерләү һәм урнаштыру.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://muslumovo.tatarstan.ru веб-адресында Мөслим муниципаль районы рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә..

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы Г.С.Романова**